| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.10.2021 Баулы шәһәре № 41

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль казнасы турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, мөлкәт белән идарә итүнең, аның сакланышының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль казнасы турындагы нигезләмәне расларга (кушымтада).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәТатарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы шәһәр Советының икътисадый үсеш, эшкуарлык, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры урынбасары,
шәһәр Советы Рәисе урынбасары К.Ф. Корбанов

Баулы шәһәр Советының
2021 елның
41нче номерлы
карарына кушымта

Положение о муниципальной казне муниципального образования «город Бавлы» Бавлинского муниципального района Республики Татарстан
Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль казнасы турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә эшләнде һәм максатларны, бурычларны, составны һәм формалаштыру чыганакларын, шулай ук Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль казнасы составына керүче муниципаль мөлкәтне исәпкә алу, аның белән идарә итү һәм эш итү тәртибен билгели.

1.2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль казнасын (алга таба - казна) хуҗалык алып бару хокукында муниципаль унитар предприятиеләргә һәм оператив идарә итү хокукында муниципаль учреждениеләргә беркетелмәгән җирле бюджет һәм муниципаль мөлкәт акчалары тәшкил итә.

1.3. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге исеменнән муниципаль казнаны тәшкил итүче муниципаль мөлкәт милекчесенең вәкаләтләрен Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

## 2. Муниципаль казна мөлкәте белән идарә итү һәм эш итүнең максатлары һәм бурычлары

2.1. Муниципаль казна белән идарә итүнең һәм эш итүнең максатлары җирле үзидарәнең матди-финанс нигезләрен булдыру һәм ныгыту:

- муниципаль берәмлек милкенең структурасын һәм составын оптимальләштерү;

- Баулы шәһәре территориясендә инвестицияләр җәлеп итү һәм эшкуарлык активлыгын стимуллаштыру;

- гражданнар-хокук алыш-бирешләре буенча Баулы шәһәренең йөкләмәләрен тәэмин итү;

- муниципаль казнаны саклап калуга ярдәм итү.

2.2. Муниципаль казна мөлкәте белән идарә иткәндә һәм эш иткәндә күрсәтелгән максатларда түбәндәге бурычлар хәл ителә:

- муниципаль казнага керүче мөлкәтнең гомуми исәбе, аның хәрәкәтен вакытында чагылдыру;

- муниципаль мөлкәттән файдалануның иң нәтиҗәле ысулларын ачыклау һәм куллану;

- муниципаль мөлкәтнең сакланышын һәм алардан максатчан билгеләнеш буенча файдалануны тикшереп тору.

## 3. Муниципаль казнаның составы һәм формалашу чыганаклары

3.1. Муниципаль казна объектлары:

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары;

- җирле үзидарә органы эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле мөлкәт;

- муниципаль милектә беркетелгән матди булмаган активлар;

- муниципаль учреждениеләргә һәм предприятиеләргә законда билгеләнгән тәртиптә беркетелмәгән башка күчемле һәм күчемсез мөлкәт.

3.2. Муниципаль казна булдыру чыганаклары түбәндәгеләр булырга мөмкин:

а) федераль дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары һәм муниципаль берәмлекләр арасында вәкаләтләр бүлешү турындагы законнарда каралган тәртиптә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенә тапшырылган;

б) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының башка муниципаль берәмлегеннән «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкенә тапшырылган;

в) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән яңадан булдырылган яисә муниципаль милек итеп сатып алынган;

г) юридик һәм физик затлар тарафыннан түләүсез Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль милкенә тапшырылган;

д) муниципаль учреждениеләр һәм муниципаль предприятиеләр бетерелгәннән соң калган;

е) суд карары буенча муниципаль берәмлек милке дип танылган хуҗасыз мөлкәт;

ж) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге милкенә гамәлдәге законнарда каралган башка нигезләр буенча кергән.

3.3. Муниципаль казна составына 3.2 пунктында күрсәтелгән чыганаклар исәбеннән төзелгән мөлкәтне кертү Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең карары нигезендә әлеге Нигезләмәгә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.4. Муниципаль казна составына керүче мөлкәткә милек хокукын формалаштыру, исәпкә алу, рәсмиләштерү һәм дәүләт теркәвенә алуны Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

3.5. Муниципаль казнаны формалаштыру һәм аның эчтәлеген финанслау Татарстан Республикасының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла.

4. Муниципаль казна объектларын исәпкә алу

4.1. Муниципаль казнаны тәшкил итүче мөлкәткә Татарстан Республикасының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге милек хокукында ия.

4.2. Муниципаль казна составына кертелгән мөлкәт балanска тапшырыла һәм Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының бухгалтерлык хисабында чагылыш табарга тиеш. Муниципаль казна мөлкәтен исәпкә алу Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрының «Муниципаль мөлкәт реестрларының җирле үзидарә органнары алып бару тәртибен раслау турында» 2011 елның 30 августындагы 424 номерлы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.3. Юридик затларга файдаланууга тапшырылган муниципаль казна милке кулланучыларда баланс счетында бухгалтерлык исәбе белән исәпләнергә тиеш.

4.4. Муниципаль казнаны тәшкил итүче мөлкәтне бәяләү юридик затларга милек хокукындагы мөлкәтне бәяләү өчен законнарда һәм башка хокукый актларда билгеләнгән кагыйдәләр буенча гамәлгә ашырыла.

5. Муниципаль казна белән идарә һәм эш итү тәртибе

5.1. Муниципаль казнаны тәшкил иткән мөлкәт гамәлдәге законнар нигезендә муниципаль мөлкәтне тапшыру турында тиешле шартнамәләр төзү нигезендә юридик һәм физик затларга файдаланууга тапшырылырга мөмкин.

5.2. Мөлкәт түбәндәге очракларда Россия Федерациясе законнарында, җирле үзидарә органының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә муниципаль казнадан төшереп калдырылырга мөмкин:

а) Баулы шәһәренең муниципаль милкеннән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкенә йә Россия Федерациясенең федераль милкенә түләүле яисә түләүсез тапшыру;

б) гамәлдәге законнарда каралган очракларда, акционерлык җәмгыятьләренә кертемнәр сыйфатында муниципаль мөлкәт кертү;

в) муниципаль предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында беркетү;

г) муниципаль учреждениеләргә оператив идарә хокукында беркетү;

д) граждан-хокукый алыш-биреш (сату, бүләк итү, алыштыру) нәтиҗәсендә мөлкәтне читләштерү;

е) суд карары законлы көченә керү;

ж) физик тузу нәтиҗәсендә муниципаль казна мөлкәтен исәптән чыгару турында карар кабул итү;

з) күчемсез мөлкәткә зыян китерү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә аның юкка чыгуы йә зыян күрүе сәбәпле барлыкка килгән югалтулар;

и) муниципаль казна мөлкәтенә муниципаль милек хокукын Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган башка нигезләр буенча туктату.

5.3. Милекне хосусыйлаштырганда муниципаль казна составыннан төшереп калдыру кануннарда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5.4. 5.2 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән очракларда муниципаль казна составыннан төшереп калдыру Баулы шәһәр Советы карары, «в» -«и» пунктчаларында - Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 6. Муниципаль казнаның сакланышын һәм максатчан файдалануын тикшереп тору

6.1. Юридик һәм физик затларга файдалануга тапшырылган муниципаль казна составына керүче мөлкәтнең сакланышын һәм максатчан кулланылышын тикшереп тору, шулай ук тапшырылган объектларны тиешенчә файдаланмаган өчен җаваплылыкка тарту Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре»

муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан милекне тапшыру турында төзелгән шартнамәләрнең шартлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Контроль барышында Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты, ихтыяҗ туганда, тапшырылган мөлкәтнең торышын һәм мөлкәтне тапшыру турындагы шартнамәләрнең шартларын үтәүне тиешенчә тикшерә.

Муниципаль казна составына керүче мөлкәтне тапшыру срогына мөлкәтне карап тоту бурычы һәм мөлкәтнең очраклы рәвештә юкка чыгуы куркынычы кулланучыга мөлкәтне тапшыру шартнамәсе төзегәндә беркетелергә тиеш.

6.2. Муниципаль казна составына керә торган мөлкәт шартнамә йөкләмәләре белән йөкләнмәгән чорда аның торышын Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тикшереп тора.